**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ӘТНӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ӨҖЕМ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

422008, Таш-Чишмә авылы, Ш.Усманов урамы, 1Б йорты

Тел.: (8-84369) 3-50-10; факс: 3-50-10

**СОВЕТ УЗЮМСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ АТНИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

422008, село Таш-Чишма, ул. Ш.Усманова, д. 1Б

Тел.: (8-84369) 3-50-10; факс: 3-50-10

# КАРАР

«04» апрель 2025 ел №109

**Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Өҗем авыл җирлеге Советы депутатларын сайлауны уздыру өчен бермандатлы сайлау округлары схемасын раслау турында**

2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы «Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль законның 18 статьясы, 2007 елның 07 маендагы 21-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Сайлау кодексының 25, 26 статьялары, Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районының «Өҗем авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 12 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районының Өҗем авыл җирлеге Советы карар итте:

1. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районының Өҗем авыл җирлеге Советы депутатларын сайлауны уздыру өчен бермандатлы сайлау округлары схемасын ун елга расларга (кушымта итеп бирелә).

2. Әлеге карарны, бермандатлы сайлау округлары схемасын, аның график сурәтен дә кертеп, 2025 елның 8 апреленнән дә соңга калмыйча Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгару юлы белән, Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районының интернет челтәрендәге рәсми сайтында (http://atnya.tatarstan.ru) адресы буенча, Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районының Өҗем авыл җирлеге торак пунктлары территорияләрендә урнашкан махсус мәгълүмат стендларында түбәндәге адреслар буенча:

Таш-Чишмә авылы, Ш.Усманов урамы, 1Б йорт (администрация бинасы);

Таш-Чишмә авылы, М.Горький урамы, 29 йорт (клуб бинасы)

Иске Өҗем авылы, Татарстан урамы, 18 йорт (клуб бинасы) халыкка җиткерергә.

3. Карар ул басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

Өҗем авыл җирлеге башлыгы: Вәлиев А.Т.

Совет Узюмского сельского поселения

Өҗем авыл җирлеге Советы

ИНН 1610000973


Өҗем авыл җирлеге Советының
2025 елның 4 апрелендәге
109 нчы номерлы карарына 1 нче кушымта

Өҗем авыл җирлеге вәкиллекле органнарына депутатлар сайлау буенча
бермандатлы сайлау округлары схемасы

| № п/п | Сайлау округы исеме | Округ чикләре | Сайлаучылар саны |
|---|---|---|---|
| 1 | 1 нче номерлы бермандатлы сайлау округы | **Таш-Чишмә авылы,** Г.Тукай урамы, Совет урамы, М.Горький урамы, № 12 – № 28 йортлар | 62 |
| 2 | 2 нче номерлы бермандатлы сайлау округы | **Таш-Чишмә авылы,** Ш.Усманов урамы, Х.Такташ урамы, Г.Кутуй урамы | 62 |
| 3 | 3 нче номерлы бермандатлы сайлау округы | **Таш-Чишмә авылы,** М.Вахитов урамы, № 25 – № 69 йортлар | 59 |
| 4 | 4 нче номерлы бермандатлы сайлау округы | **Таш-Чишмә авылы,** М.Җәлил урамы, М.Вахитов урамы, № 1 – № 24 йортлар | 55 |
| 5 | 5 нче номерлы бермандатлы сайлау округы | **Таш-Чишмә авылы,** М.Горький урамы, № 1 – № 11 йортлар,<br>**Мокшы авылы** | 59 |
| 6 | 6 нчы номерлы бермандатлы сайлау округы | **Иске Өҗем авылы,** Татарстан урамы, Болгар урамы, № 2 - № 16 (җөп санлы йортлар), Такташ урамы | 60 |
| 7 | 7 нче номерлы бермандатлы сайлау округы | **Иске Өҗем авылы,** Болгар урамы, № 1 - № 15 (так санлы йортлар), Центральная урамы | 66 |

Өҗем авыл җирлеге Советының
2025 елның 4 апрелендәге
109 нче номерлы карарына 2 нче кушымта


**Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Өҗем авыл җирлеге Советы депутатларын сайлауны уздыру өчен бермандатлы сайлау округлары схемасының график сурәте**




Деревня Старый Узюм

Село Таш-Чишма




деревня Мокша